| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.09.2024 г. Казань № 2122

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибен раслау турында» 14.11.2023 ел, № 2707 боерыгына үзгәреш кертү турында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибен раслау турында» 14.11.2023 ел, № 2707 боерыгына үзгәрешләр кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры урынбасары Г.К. Зәкәриевага йөкләргә.»;

Әлеге боерык белән расланган, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Әлеге Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибе (алга таба –

бюджет керемнәре администраторы, Тәртип) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану процедурасын билгеләү максатыннан эшләнгән.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Бюджет керемнәре администраторы Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарны түбәндәге очракларда кабул итә:

а) Бюджетка түләүләр түләүченең – физик затның – үлеме яки аны Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнарда билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан итү;

б) «Банкротлык турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, шәхси эшмәкәрнең күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аны түләү бурычын үтәүдән ул азат ителгән, Бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә – банкротлык процедурасын тәмамлануы;

в) Бюджетка түләүләр түләүчене – оешманы – оешманың милке җитмәү һәм (яисә) күрсәтелгән оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле Бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә ликвидацияләү;

г) штраф рәвешендә җәзага тартылган хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар куллану яисә суд тарафыннан карар кабул ителү, бу карар нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, югалта;

д) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен бурыч күләме бурычлыга карата бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаган очракта, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт узган булса, «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлеше 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда, суд приставы-башкаручының башкарма производствоны тәмамлау турында карар чыгару;

е) суд тарафыннан бурычлыны банкрот дип тану турындагы гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле банкротлык турындагы эш буенча производствоны туктату турында акт кабул итү;

ж) теркәүче орган карары буенча юридик затны Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан чыгару һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда оешманың милке җитмәү һәм аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле Бюджетка түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә - «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлеше 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару производствосын тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан алдан чыгарылган карарның булуы.

Теркәү органының «Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне дәүләт теркәве турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затны Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан чыгару турында карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган Бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) хисабында торгызылырга тиеш.»;

4 пунктта:

беренче абзацта «карар» сүзен «Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карар» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «2 пунктының «в» пунктчасында» сүзләрен «2 пунктының «б» пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «2 пунктының «г» пунктчасында» сүзләрен «2 пунктының «в» пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы «2 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «2 пунктының «г» пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «(Тәртипнең 2 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән очракта)» сүзләрен «(Тәртипнең 2 пунктындагы «д», «е», «ж» пунктчаларында күрсәтелгән очракларда)» сүзләренә алмаштырырга.;

5 пунктта «карарны әзерләү һәм кабул итү максатларында» сүзләрен «Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану эшен оештыру максатыннан» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«12. Комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча, Тәртипнең 11 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очракта, утырыш уздырылган көннән алып ун эш көне дәвамында Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16. Тәртипнең 11 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм утырышта булган Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм министрга хәбәр итү өчен җибәрелә.».

Министр М.М.Миңнуллин